

Сонгы берничә елда электросамокатлар аеруча популяр булды. Кемнәрдер аны хуплый, ә кемнәрдер сvгә. Шәһәрдә генә тvгел, авыл юлларында да бу тор транспортта “выжлап” vтеп китәләр: аяк астына караганнары бик аз. ГИБДД бvлекчәсенен олкән инспекторы, полиция капитаны Ольга Аносова билгеләп vткәнчә, мондый транспорт чаралары белән идарә итvче гражданнар еш кына юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозалар яки vзләрен тиешенчә тотмыйлар.       Самокатлар сезоны ачылды, сак булыгыз, дип кисәтә. Барысы турында Ольга Владимировна:

- Республика территориясендә Мордовия Дәvләт автоинспекциясе хезмәткәрләре ике тәгәрмәчле транспорт чаралары йортvчеләре катнашында юл-транспорт һәлакәтләрен кисәтv, мототранспорт йортvчеләре тарафыннан юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозуны ачыклау һәм кисәтv максатларында «Мотоцикл» оператив-профилактик чарасын оештырдылар.

Рейд тикшерvләре барышында ГИБДД инспекторлары мотоцикл, мопед һәм скутер йортvчеләре белән актив эш алып баралар. Оператив-профилактик чара вакытында әлеге транспорт чараларын идарә итvче машина йортvчеләр тарафыннан 80нән артык хокук бозу очрагы ачыкланган. Кvпчелек хокук бозучыларнын тиешле категорияле йортv таныклыгы да, махсус саклагыч жайланмалары да булмаган.

Мәсәлән, Ардатовта дәvләт автоинспекциясе хезмәткәрләре тарафыннан 42 яшьлек мотоцикл йортvчесе туктатыла, ул аны йортv таныклыгы, транспорт чарасына документлар булмаганда, саклагыч мотошлемсыз, шулай ук алкоголь исерек хәлдә идарә итә. Тикшерv барышында шулай ук гражданнын исерек килеш йоргән очен административ жаваплылыкка тартылуы ачыкланды. Машина йортvчегә карата РФ ЖК 264 маддәсе буенча материал тупланган, шулай ук дvрт административ материал тозелгән, мотоцикл тоткарланган һәм махсус тукталышка урнаштырылган.

